**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6510**
**01.11.2018**

«2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, шәһәр Уставының 53 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын тормышка ашыру чараларын финанслауны шәһәр бюджетының «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 0707, «Мәгариф өлкәсендәге башка мәсьәләләр» 0709, «Мәдәният» 0801 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 2019 елда – 2066,8 мең сум, 2020 елда – 2066,8 мең сум, 2021 елда – 2066,8 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 1 ноябрендәге
6510 нчы карарына
кушымта

«2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт
милли сәясәтен тормышка ашыру»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт
милли сәясәтен тормышка ашыру»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру программасы» (алга таба - программа). |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 нчы Указы белән расланган Россия Федерациясенең 2025 елга кадәрге чорга дәүләт милли сәясәте стратегиясе.<br>Россия Федерациясенең 2014 елның 15 апрелендәге 317 нче карары белән расланган «2013-2020 елларга мәдәниятне һәм туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы.<br>Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 нче Указы.<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 18 декабрендәге 1006 нчы карары. |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе (алга таба – мәдәният идарәсе). |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе. |
| Программаның максаты | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халык вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара татулыкны һәм бердәмлекне саклау, гомумроссия гражданлык бердәмлеген (Россия милләтенең) ныгыту, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе. |
| Программаның бурычлары | 1. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлеген камилләштерү.<br>2. Гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга, этникара һәм конфессияара татулыкны һәм килешүчәнлекне саклауга |

<table>
<tr><td></td><td colspan="5">булышлык итү, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе өчен шартлар тудыру.<br>3. Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру.<br>4. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин ителеше.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2019-2021 еллар.</td></tr>
<tr><td rowspan="9">Программаны финанслауның елларга бүленгән күләмнәре һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2019 ел</td><td>2020 ел</td><td>2021 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>6 200,4</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>6 200,4</td></tr>
<tr><td colspan="5">Искәрмә: финанслау күләмнәре прогноз характерына ия һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, аларга ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Программаны тормышка ашыруның йомгаклау нәтиҗәләре:<br>- интернационализм, бердәмлек, милли һәм дини үзара килешүчәнлек культурасын тарату;<br>- башка этникара һәм конфессияара җәмгыятьләрнең вәкилләренә карата толерантлы аң формалаштыру;<br>- яшьләр мохитендә этникара бердәмлек һәм толерантлык атмосферасын ныгыту һәм җәелдерү;<br>- муниципаль берәмлек территориясендә толерантлык, гражданлык бердәмлеге, башка мәдәниятләргә хөрмәт белән карау идеяләрен пропагандалау һәм тарату өчен бердәм мәгълүмати киңлек булдыру, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруга контроль оештыру системасы</td><td colspan="5">Программа үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа алымы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

«2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру программасы» Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 нче Указы нигезендә эшләнгән. Әлеге Концепция нигезендә, Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең милләтара мөнәсәбәтләре һәм этномәдәни үсеш өлкәсе дәүләт милли сәясәтенең объекты булып тора.

Татарстан Республикасының Дәүләт милли сәясәте концепциясе принципларына таянып, Программа, милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар вәкилләренең этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен оптималь шартлар тудыруның максатларын, принципларын, төп юнәлешләрен, бурычларын һәм механизмнарын билгели.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы тотрыклылык, үзара татулык һәм төрле этник төркемнәр һәм конфессияләр вәкилләренең хезмәттәшлек итүләре белән характерлана. Үзара ихтирам һәм ышанычка корылган милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр муниципаль хакимият органнарының иҗтимагый этномәдәни берләшмәләр һәм башка гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлегендә аеруча кайгыртучанлык предметы булып тора.

Яр Чаллы шәһәре хәзерге заман Татарстан территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең тыгыз этномәдәни үзара йогынтысы һәм традицияләрнең үзара саклануы белән характерлана торган күпмилләтле һәм поликонфессияле Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге санала. Әлеге процесста традицион рәвештә әйдәп баручы ролен Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче барлык калган халыклар вәкилләренә карата күпчелекне тәшкил иткән татар һәм рус халыклары вәкилләре уйный.

Төрле мәдәният һәм дин вәкилләренең Яр Чаллы шәһәрендә озак бергә яшәү дәверендә барлыкка килгән дус-туганлык традицияләре хәзерге вакытта да саклана. Гомумроссия гражданлык бердәмлеген формалаштыру, яшь буынны Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең мәдәниятенә, теленә, традицияләре һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карау рухында тәрбияләү, белем бирү процессында гуманитар юнәлешнең ролен күтәрү буенча максатчан эшләү моңа ярдәм итә.

Милли җәмгыятьләр каршында 11 милли мәдәниятне сөючеләр клубы эшли, алар: азәрбайҗан мәдәниятен сөючеләр клубы, «Наири» әрмән мәдәниятен сөючеләр клубы, «Киликиа» әрмән мәдәниятен сөючеләр клубы, мари мәдәниятен сөючеләр клубы, «Inspiration» яшьләр клубы – немец мәдәниятен сөючеләр клубы, лезгин мәдәниятен сөючеләр клубы, удмурт мәдәниятен сөючеләр клубы, башкорт мәдәниятен сөючеләр клубы, керәшен мәдәниятен сөючеләр клубы, чуаш мәдәниятен сөючеләр клубы, таҗик мәдәниятен сөючеләр клубы. Аларда талантлы укытучылар – педагогик белемгә ия, милли җәмгыятьләр вәкилләре хезмәт куя. Һәр клубта уртача 15 әр кеше шөгыльләнә, 5 яшьтән 30 яшькә кадәрге төрле яшьтәге барлыгы 150 кеше зур канәгатьләнү белән милли клубларның дәресләренә йөри.

Идарә системасы, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм массакүләм мәгълүмат чаралары кадрларының этномәдәни үсеш, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр, мигрантларны хокукый агарту, аларның җәмгыятьтәге социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе мәсьәләләрендә квалификацияләрен һәм компетентлыгын күтәрү мөһим бурыч булып тора.

Конфессияара татулык һәм бердәмлекне, мигрантларның социомәдәни адаптациясен һәм интеграциясен тәэмин итүдә гражданлык җәмгыяте институтлары

зур роль уйный. Алар арасында Татарстан халыклары Ассамблеясының Яр Чаллы филиалы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы дини һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара эшчәнлек Советы мөһим урын тота.

Шәһәрдә 41 дини оешма, шул исәптән 20 – мөселман, 1 – православие, 1 – борынгы йола, 9 – протестант, 1 еврей оешмасы бар.

Традицион дини агымнар вәкилләре үз хезмәтләрен башкарганда халык арасында дини һәм конфессияара конфликтлар килеп чыгуны булдырмауга юнәлдерелгән агарту эшләре алып баралар.

Дин башлыклары шәһәр һәм район чараларында актив катнашалар, агарту эше белән шөгыльләнәләр.

Традицион дини берләшмәләр шәһәр Башкарма комитеты белән даими үзара эшчәнлек алып баралар.

Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарының милли һәм дини берләшмәләр җитәкчеләре белән үзара эшчәнлеге нәтиҗәсендә 2018 елда Яр Чаллы шәһәре территориясендә милләтара һәм динара конфликтлар булмады.

Милләтара мөнәсәбәтләрне үстерү һәм гармонияле итү проблемасы комплекслы якын килүне, аны максатчан программа алымнары белән хәл итүне сорый. Аларга түбәндәгеләр керә:

- этникара интеграция һәм бердәмлек проблемасының масштаблылыгы һәм күпкырлылыгы;

- милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салу процессының күп аспектлылыгы;

- район территориясендә яшәүче халыклар һәм төрле этник төркемнәр вәкилләре арасында гомумгражданлык бердәмлеген формалаштыру процессының социаль, этник һәм икътисадый аспектларының үзара бәйлелеге;

- дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруда, этноконфликтларны һәм экстремизмны профилактикалауда башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, милли-мәдәни берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең үзара эшчәнлек алып баруының кирәклеге.

«2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасы муниципаль берәмлектә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең позитив характерын саклауга һәм үзара хөрмәт һәм дус-туганлыкның күп гасырлар буена яшәп килгән традицияләре нигезендә гражданнарның этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә булышлык итүгә юнәлдерелгән. Программа этникара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге проблемаларны булдырмау һәм Яр Чаллы шәһәре күпмилләтле халкының этномәдәни үсешен яхшырту мөмкинлеге бирәчәк.

## 3 бүлек. Әлеге программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау, гомумроссия гражданлык бердәмлеген (Россия милләтенең) ныгыту, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе.

Программаның бурычлары:

1) Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлеген камилләштерү;

2) Гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга, этникара һәм конфессияара татулыкны һәм килешүчәнлекне саклауга булышлык итү, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе өчен шартлар тудыру;

3) Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру;

4) Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин ителеше.

Күрсәтелгән максатлар һәм бурычларны үтәүгә ирешү программага кергән чаралар кысаларында гамәлгә ашырылачак.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

| Т/с | Этапның исеме | Тормышка ашыру чоры |
|---|---|---|
| 1 | Программаны тормышка ашыру | 2019-2021 еллар |
| 2 | Йомгаклау | 2021 елның 4 кварталы |

## 5 бүлек. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслауның күләме (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 6 200,4 | 2 066,8 | 2 066,8 | 2 066,8 |
| Барлыгы | 6 200,4 | 2 066,8 | 2 066,8 | 2 066,8 |

## 6 бүлек. Нәтиҗәлелекне бәяләү һәм көтелгән нәтиҗәләр

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге төрле халыклар вәкилләренең толерантлыгы һәм мәдәниятә, телгә һәм традицияләргә ихтирамы үсү нигезендә бәяләнәчәк. Социаль тотрыклылыкны, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм этномәдәни үзенчәлекне саклау һәм Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар вәкилләренең социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- Яр Чаллы шәһәре территориясендә террорчылык актлары эшләнү ихтималын минимизацияләү;
- халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен күтәрү;
- Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартларны яхшырту;
- мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе дәрәҗәсен саклау.

| Т/с | Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы |
|---|---|---|
| 1. | Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның өлеше | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N – Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның саны;<br>D – Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның гомуми саны. |
| 2. | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни (бу – гражданнарның этник, этномәдәни яки дини принциплар буенча традицион эшләүче яки күптән түгел үзеннән-үзе оешкан берләшмәләр) үсешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның санын ел саен арттыру планлаштырылган. |

**«2019 - 2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, программаның чаралары, чараларны финанслау**

| Чараларның исеме | Башкару чылар | Тормышка ашыру сроклары | Максатчан индикаторлар һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганаклары | Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 ел (бәяләү) | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Максатларның исеме: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм дуслыкны саклау, гомумроссия гражданлык бердәмлеген (Россия милләтенең) ныгыту, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе | | | | | | | | | | | | |
| | | 2019-2021 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның өлеше, % | 64,4 | 65,6 | 66 | 66,4 | - | - | - | - | |
| | | 201-2021 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның саны, кеше | 41 535 | 47 520 | 49 374 | 51 191 | - | - | - | - | |

| Чараларның исеме | | Башкару чылар | Тормышка ашыру сроклары | Максатчан индикаторлар һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганаклары | Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 ел (бәяләү) | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | |
| 1 | | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Бурычның исеме: 1. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлеген камилләштерү | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Чараларны оештыручылар ягыннан «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ санлы Федераль закон таләпләре нигезендә гавами чаралар оештыру һәм үткәрү тәртибен саклауны тәэмин итү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгать челек белән элемтә идарәсе | 2019-2021 еллар | Үткәрелгән гавами чаралар буенча әзерләнгән хисаплар саны, берәмлек | 40 | 40 | 41 | 42 | - | - | - | - | Гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгыту (Россия милләтенең) |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Милли һәм дини нигездә экстремизмны профилактикалау максатында милли-мәдәни җәмгыятьләр, милли диаспоралар белән регуляр очрашулар үткәрү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгать челек белән элемтә идарәсе | 2019-2021 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеше |
| 3 | Милли җәмгыятьләр рәисләренең Татарстан халыклары Ассамблеясының күчмә утырышларында катнашуы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеше, милли һәм дини нигездә экстремизмны профилактикалау |
| Бурычның иseме: 2. Гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга, этникара һәм конфессияара татулыкны һәм килешүчәнлекне саклауга булышлык итү, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе өчен шартлар тудыру. | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында, Интернет челтәрендә этникара һәм динара мөнәсәбәтләрне ныгытуга, террорчылык | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында чыккан материаллар саны, берәмлек | 5 | 6 | 7 | 8 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен яхшы атмосфера булдыру |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм экстремизмны профилактикалауга, дини һәм этник түзеп тора алмаучанлык һәм дискриминациягә каршы торуга булышлык итүче мәгълүматлар урнаштыру, шулай ук шәһәрдә үткәрелгән этникара һәм динара мөнәсәбәтләрне ныгытуга булышлык итүче чараларны яктыртып бару | | | | | | | | | | | | |
| 2 | Дини оешмаларга конфессияара үзара аңлашуга һәм татулыкка булышлык иткән мәдәни-агарту һәм иганәчелек программаларын тормышка | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгать челек белән элемтә идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | фактта | фактта | фактта | фактта | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен яхшы атмосфера булдыру |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ашыруда ярдәм күрсәтү (Раштуа, Пасха, Чукындыру хөрмәтенә тәре йөреше, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме, Хәтер көннәре) | | | | | | | | | | | | |
| 3 | Казан епархиясе рус православие чиркәвенең Кама аръягы благочиниесы һәм ТР мөселманнарының Диния нәзарәте мөхтәсибәтенең берлектә эшләве өчен шартлар тудыру: социаль, иганәчелек, өмәләр, чараларны ачу, үзара визитлар, түгәрәк өстәлләр һ.б. | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгать челек белән элемтә идарәсе | 2019-2021 еллар | Үткәрелгән чараларның саны, берәмлек | 2 | 3 | 4 | 5 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен яхшы атмосфера булдыру |
| 4 | «Ак мәчет» мәчетендә яшь | Башкарма комитет | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 160 | 162 | 164 | 166 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Коръән укучыларның ел саен үткәрелә торган республикаара конкурсын уздыруда ярдәм күрсәтү | ның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгать челек белән элемтә идарәсе | | | | | | | | | | | бердәмлеккә булышлык итү өчен яхшы атмосфера булдыру |
| 5 | Милли җәмгыятьләр рәисләренең квартал саен Федераль Миграция хезмәте идарәсе вәкилләре белән очрашуы | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеше, милли һәм дини нигездә экстремизмны профилактикалау |
| Бурычның исеме: 3. Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру. | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 1 000 | 1 005 | 1 010 | 1 015 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 2 | Идел буе халыклары ның | Башкарма комитетн ың | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | - | 40 | 45 | 50 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Мәдәниятләр диалогы» фестивален оештыру һәм үткәрү | мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | | | | | | | берәмлеге бюджеты | | | | социальләштерү |
| 3 | «Татар малае» мунииипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (1-4 сыйныфлар) | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 100 | 105 | 110 | 115 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 4 | «Татар малае» мунииипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (5-8 сыйныфлар) | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2016-2018 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 100 | 105 | 110 | 115 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 5 | «Татар малае», «Татар кызы» мунииипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (мәктәпкәчә яшьтәгеләр) | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 200 | 205 | 210 | 215 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 70,0 | 70,0 | 70,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 6 | «Мин татарча сөйләшәм» | Башкарма комитет | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 100 | 105 | 110 | 115 | Яр Чаллы шәһәре | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | республика конкурсының муниципаль турын оештыру | ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | | | | | | | муниципаль берәмлеге бюджеты | | | | мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 7 | «Татар кызы» муниипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 54 | 56 | 60 | 63 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 8 | Туган тел көнен үткәрү | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 49 | 53 | 57 | 60 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 9 | «Милләтләр дуслыгы» шәһәр программасын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 1 000 | 1 005 | 1 010 | 1 015 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең балалар коллективлары арасында «XXI гасыр йолдызчыклары» муниипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 300 | 305 | 310 | 315 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 11 | Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык сакчылары изге Петр һәм Феврония Муромскийлар истәлеге көненә чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 300 | 305 | 310 | 315 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 12 | Милли җәмгыятьләр спартакиадасын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | - | 200 | 210 | 215 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Бердәм мәдәни киңлек формалаштыру, шәһәрдә яшәүче халыклар вәкилләренең милли спорт төрләрен, традицион уеннарын популярлаштыру |
| 13 | «Ариран» корея җәмгыяте | Башкарма комитетның | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 120 | 130 | 140 | 150 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Корея халыкларының мәдәни төрлелеген |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | белән берлектә Көнчыгыш Яңа елын оештыру һәм үткәрү | мәдәният идарәсе | | | | | | | берәмлеге бюджеты | | | | һәм традицияләрен саклау |
| | Таҗик, лезгин, азербайҗан, үзбәк, казах, башкорт җәмгыятьлә рендә «Нәүрүз» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 200 | 210 | 215 | 220 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Халыкларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 14 | Яр Чаллы шәһәрендә «Нәүрүз» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | - | 500 | 520 | 550 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Халыкларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 15 | «Уяв» чуаш милли-йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 150 | 170 | 190 | 200 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 16 | «Иван Купала» славян халык-йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021еллар | Катнашучылар саны, кеше | 1 000 | 1 010 | 1 015 | 1 020 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | «Питрау» шәһәр халык-йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 500 | 550 | 600 | 650 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 18 | «Нардуган» традицион керәшен йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 800 | 830 | 850 | 880 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 19 | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен «Салават күпере төсләре» күңел ачу-танып-белү программасы | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Концертлар саны, берәмлек | 10 | 11 | 12 | 13 | - | - | - | - | Балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 20 | Милли җәмгыятьләр яшьләре өчен «Мәхәббәт хакына» конкурс-күңел ачу программасы | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 234 | 245 | 255 | 270 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 15,0 | 15,0 | 15,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 21 | Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли | Башкарма комитет ның мәдәният | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 234 | 245 | 255 | 270 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | 15,0 | 15,0 | 15,0 | Балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | курчак» шәһәр конкурсы | идарәсе | | | | | | | бюджеты | | | | |
| 22 | Милли җәмгыятьләр нең «Дус-туганлык – иң зур байлык» фестивале | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 900 | 920 | 950 | 980 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 130,0 | 130,0 | 130,0 | Шәһәрдә һәм республикада яшәүче халыкларның мәдәни күптөрлелеген саклау һәм аңа карата позитив кыйммәтләр, хөрмәт формалаштыру |
| 23 | Туган тел фестивале | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 314 | 320 | 330 | 340 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар телләренең телләр күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 24 | Урта гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен милли җәмгыятьләр нең бүлмәләре буенча экскурсияләр оештыру | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Экскурсияләр нең саны, берәмлек | 30 | 30 | 30 | 30 | - | - | - | - | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 25 | Башкорт җәмгыяте белән берлектә «Карга боткасы» милли бәйрәмен | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 700 | 750 | 800 | 850 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар мәдәниятенең милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | | | |
| 26 | «Терендез» әрмән милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | - | 150 | 160 | 170 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар мәдәниятенең милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 27 | Татарстан Республикасы фин-угыр халыкларының «Без бер агач тармаклары» халык иҗаты фестивален оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 2000 | 2020 | 2050 | 2080 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 100,0 | 100,0 | 100,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 28 | «Шорыкйол пайрем» мари милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | - | 150 | 160 | 170 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 29 | «Каз өмәсе» халык-йола бәйрәме | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 600 | 650 | 700 | 750 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 30 | «Май чабу» шәһәр бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 8 000 | 8 050 | 8 150 | 8 200 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 31 | «Милли бәйрәмнәр» милли бәйрәмнәр буенча фольклор кич утырулар» шәһәр проекты | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | - | 110 | 120 | 130 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балалар һәм яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 32 | «Сабан туе» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 10 000 | 13 000 | 14 000 | 15 000 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 332,8 | 332,8 | 332,8 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 33 | Татарстан Республикасы көне һәм Яр Чаллы шәһәре көненә багышланган шәһәр бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 12 000 | 13 200 | 13 500 | 13 800 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 150,0 | 150,0 | 150,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 34 | «Идел буе этносы һәм мәдәнияте» мәдәни-мәгариф проекты | Башкарма комитет ның мәдәният идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | - | 100 | 105 | 110 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 72,0 | 72,0 | 72,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 35 | Чит ил студентлары форумы | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 120 | 125 | 130 | 135 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 36 | Татар яшьләре форумы | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 50 | 60 | 65 | 70 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 37 | «Татар егете» төбәк проектын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 75 | 80 | 85 | 90 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләр арасында үз халкының мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү, гражданның рухый шәхесен һәм үз иленең патриотын тәрбияләү |
| 38 | «Серле сандык» шәһәр милли иҗат проектын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 80 | 85 | 90 | 95 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Проектта катнашучыларның толерант аңын формалаштыру һәм Яр Чаллы шәһәрендә һәм төбәктә яшәүче халыкларның |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | идарәсе | | | | | | | | | | | милләтара мөнәсәбәтләрен ныгыту өчен шартлар тудыру |
| 39 | «Бергә» ток-шоуы | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | - | 105 | 110 | 115 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 12,0 | 12,0 | 12,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 40 | «Халкым чишмәсе» төбәк яшьләренең татар милли иҗат фестивален оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 гг. | Катнашучылар саны, кеше | 165 | 170 | 175 | 180 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 41 | Эшкә урнашу теләге булган чит ил студентлары өчен хезмәт законы нигезләре буенча курслар үткәрү | Башкарма комитет ның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 50 | 55 | 60 | 65 | - | - | - | - | Чит ил студентлары арасында легаль рәвештә эшкә урнашканнарның санын арттыру |

| Бурычның исеме: 4. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин ителеше | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Конфессияара һәм милләтара мөнәсәбәтләрнең торышына квартал саен мониторинг үткәрү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгать челек белән элемтә идарәсе | 2019-2021 еллар | Мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмати-аналитик материаллар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен яхшы атмосфера булдыру |
| 2 | Дини оешмалар һәм культ корылмалары турында мәгълүматлар банкын квартал саен формалаштыру һәм актуальләштерү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгать челек белән элемтә идарәсе | 2019-2021 еллар | Мәгълүматлар базасын яңартуларның саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен яхшы атмосфера булдыру |
| 3 | Туган телдә (татар, рус) иң яхшы дәрес һәм чаралар үткәрү буенча җыентык бастырып чыгару | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | 2019-2021 еллар | Данәләр саны | 100 | 100 | 100 | 100 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балалар һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Шәһәрнең nabchelny.ru рәсми сайтында һәм шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында чараларны анонслау, пост-релизлар бастыру | | 2019-2021 еллар | Басылган материаллар, анонслар, телевизион тапшырулар, интервью һәм чыгышлар саны | 15 | 16 | 17 | 18 | - | - | - | - | Толерантлык идеяләрен пропагандалау һәм тарату, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне саклау өчен бердәм мәгълүмати киңлек формалаштыру |

## 7 бүлек. Авырлыклар һәм авырлыклар белән идарә итү чаралары

Финанс авырлыклары Программаны тормышка ашыру максатларына бюджет ресурсларының чикләнгән булуына, шулай ук программа чараларын тормышка ашыру барышында бюджет акчаларын нәтиҗәле файдаланмау ихтималына бәйле. Авырлыклар белән идарә итү өчен таләп ителгән бюджет финанславы күләме чаралар үткәрүгә сметалар белән нигезләнә.

Оештыру авырлыклары белән идарә итү чаралары сыйфатында түбәндәгеләр файдаланыла:

- эш планнарын төзү, конкрет үтәүчеләрнең чараларны үтәүләренә җаваплылыкларын ныгыту.

## 8 бүлек. Программаны үтәүгә контрольне оештыру системасы

Программаны үтәүгә контрольне оештыру түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

1) башкаручылар программаның заказчысы – Башкарма комитетка финанс хисаплары тапшыралар;

2) башкаручылар тарафыннан финанс хисапларын тапшыруның периодик рәвештә кабатланып торуы – ел саен;

3) башкаручылар ел саен программаның заказчысына программаны тормышка ашыру буенча текстлы хисап бирәләр.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева